# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасында**
**музейлар һәм музей эше турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

1 бүлек. **Гомуми нигезләмәләр**

1 статья. **Әлеге Законның кулланылу өлкәсе**

1. Әлеге Закон Татарстан Республикасында музейларны оештыру һәм аларның эшчәнлеге үзенчәлекләрен җайга сала, музей эше өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының вәкаләтләрен, шулай ук Татарстан Республикасы музейлары һәм Татарстан Республикасында музей әйберләре һәм музей тупланмалары турындагы белешмәләрне системалаштыру рәвешен билгели.

2. Әлеге Закон Татарстан Республикасында гамәлдә булган һәм яңадан төзелә торган барлык музейларга кагыла.

2 статья. **Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында Татарстан Республикасы законнары**

Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында Татарстан Республикасы законнары Россия Федерациясе Конституциясенең, федераль законнарның, Татарстан Республикасы Конституциясенең тиешле нигезләмәләренә таяна һәм Татарстан Республикасы законнарыннан, әлеге Законнан һәм бүтән норматив хокукый актлардан гыйбарәт.

3 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр һәм терминнар**

Әлеге Закон максатларында «Россия Федерациясе Музей фонды һәм Россия Федерациясендә музейлар турында» 1996 елның 26 маендагы 54-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 3 статьясында билгеләнгән төп төшенчәләр һәм терминнар, шулай ук түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

1) музей-тыюлык (музей-усадьба) – мәдәни һәм табигый мирасның тулаем территориаль комплексларын, мәдәни кыйммәтләрне (шул исәптән музей әйберләрен һәм музей тупланмаларын) аларның традицион, тарихи (мәдәни һәм табигый) мохитендә саклауны, торгызуны, өйрәнүне, куллануны һәм халыкка тәкъдим итүне тәэмин итү өчен милекче тарафыннан оештырылган музей;

2) музей эше – мәдәни-агарту, мәгълүмат, фәнни һәм белем бирү эшчәнлегенең аның бурычларына музейлар челтәрен булдыру һәм үстерү, Татарстан Республикасының мәдәни кыйммәтләрен музейлар һәм башка оешмалар тарафыннан туплауны, исәпкә алуны, саклап тотуны, саклауны, өйрәнүне һәм куллануны оештыру, музейлар хезмәткәрләре кадрларын әзерләү, музейларны үстерүне фәнни һәм методик яктан тәэмин итү, гражданнарның мәдәни кыйммәтләрдән аларны өйрәнү, популярлаштыру, фәнни бастырып чыгару, гражданнарны рухи-эстетик тәрбияләү максатларында файдалана алуын тәэмин итүче тармагы;

3) музей эшчәнлеге – мәдәният өлкәсендәге эшчәнлекнең музей әйберләрен һәм музей тупланмаларын, мәдәни һәм табигый мирас объектларын һәм матди булмаган традицион мәдәният үрнәкләрен үз эченә алган мәдәни байлыкны ачыклауга, туплауга, саклауга, өйрәнүгә һәм халыкка тәкъдим итүгә юнәлдерелгән махсуслаштырылган төрләренең берсе;

4) музей белгече – квалификациясе һәм һөнәри күнекмәләре булган, музей эшчәнлегенең төп төрләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итүче музей хезмәткәре;

5) Татарстан Республикасы музейлары реестры – Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм (яисә) гамәлдә булган музейлар һәм музейларның аерымланган структур бүлекчәләре турында белешмәләре булган исемлек;

6) Татарстан Республикасында музей әйберләренең һәм музей тупланмаларының дәүләт каталогы – Татарстан Республикасы территориясендәге музей әйберләре, музей тупланмалары һәм бүтән мәдәни кыйммәтләр турында белешмәләре булган мәгълүмат базасы.

## 2 бүлек. **Музей эше өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының вәкаләтләре**

### 4 статья. **Музей эше өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре**

Музей эше өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) Татарстан Республикасында музей эшен һәм музейлар эшчәнлеген оештыруны законнар белән җайга салу, музей эше өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарының үтәлүен тикшереп тору;

2) музей эше өлкәсендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында закон чыгару инициативасы хокукын гамәлгә ашыру;

3) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы музейларына салым ташламалары һәм бүтән ташламалар билгеләү;

4) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

**5 статья. Музей эше өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

Музей эше өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) мәдәниятне үстерү өлкәсендә Татарстан Республикасында гамәлгә ашырыла торган дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен исәпкә алып, музей эше өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен гамәлгә ашыру;

2) Татарстан Республикасы исеменнән музей эше өлкәсендәге шартнамәләргә һәм килешүләргә кул кую;

3) музей эше өлкәсендә республиканың максатчан программаларын, Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актларын эшләүне, кабул итүне һәм гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

4) дәүләт музейларын (Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланა торган исемлектәге федераль дәүләт музейларыннан тыш) төзү һәм аларга ярдәм итү тәртибен билгеләү;

5) музейлар һәм музей эше өлкәсендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары үтәлүен оештыру;

6) Татарстан Республикасы дәүләт музейларын үстерү өчен ярдәм күрсәтүне тәэмин итү һәм шартлар булдыру;

7) Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей әйберләрен һәм музей тупланмаларын саклауга һәм куллануга юнәлдерелгән шартлар булдыру һәм аларны финанслауны тәэмин итү;

8) музей эше өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүне финанслау тәртибен билгеләү;

9) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә аның карамагына кертелгән бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

**6 статья. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә дәүләт җайга салуын гамәлгә ашыруга вәкаләтле органының музей эше өлкәсендә вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә дәүләт җайга салуын гамәлгә ашыруга вәкаләтле органының музей эше өлкәсендә вәкаләтләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей әйберләренә һәм музей тупланмаларына карата Татарстан Республикасы исеменнән мөлкәти һәм

мөлкәти булмаган шәхси хокукларны һәм бурычларны, шулай ук дәүләт тикшереп торуын гамәлгә ашыру;

2) Татарстан Республикасында гамәлгә ашырыла торган республика дәүләт мәдәни сәясәтенең төп юнәлешләрен исәпкә алып, музей эше өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтен башкаруны һәм гамәлгә ашыруны турыдан-туры тәэмин итү;

3) музей эше өлкәсендә республиканың максатчан программаларын, Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актларын эшләү һәм үз вәкаләтләре чикләрендә аларны гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

4) Россия Федерациясе Музей фондыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү юлы белән гражданнарның мәдәни тормышта катнашуга хокукларына гарантияләрне тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру;

5) Татарстан Республикасында музей эшен үстерү өчен шартлар тудыру;

6) Татарстан Республикасында музей әйберләренең һәм музей тупланмаларының дәүләт каталогын алып бару;

7) Татарстан Республикасы музейлары реестрын алып бару;

8) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә аның карамагына кертелгән бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

7 статья. **Музей эше өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары музей эше өлкәсендә үз вәкаләтләрен законнар нигезендә гамәлгә ашыралар.

3 бүлек. **Татарстан Республикасында музей әйберләре һәм музей тупланмалары**

8 статья. **Татарстан Республикасында музей әйберләренә һәм музей тупланмаларына милек хокукы**

1. Татарстан Республикасында музей әйберләре һәм музей тупланмалары дәүләт, муниципаль, шәхси һәм башка милек рәвешләрендә булырга мөмкин.

2. Татарстан Республикасы милкендә түбәндәге музей әйберләре һәм музей тупланмалары бар:

1) Федераль закон кабул ителгәнгә кадәр Татарстан Республикасы милкендә булган, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбенә сатып алынган һәм оператив идарә итү өчен беркетелгән яисә милек рәвешенә һәм нинди ведомствога буйсынуына бәйсез рәвештә музейларга һәм башка оешмаларга куллануга тапшырылган;

2) Татарстан Республикасы дәүләт музейлары, Татарстан Республикасының башка дәүләт учреждениеләре тарафыннан аларның гамәлгә куючылары акчалары исәбенә яки үз акчалары исәбенә сатып алынган йә башка рәвешчә алынган.

3. Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасы милкенә музей әйберләре һәм музей тупланмалары Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә дәүләт җайга салуын гамәлгә ашыруга вәкаләтле органы, Татарстан Республикасы дәүләт музейлары тарафыннан сатып алыналар.

4. Татарстан Республикасының дәүләт милкендәге музей әйберләрен һәм музей тупланмаларын Россия Федерациясе Музей фонды составына кертү һәм аның составыннан аларны чыгару федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

9 статья. **Татарстан Республикасы милкендәге музей әйберләре һәм музей тупланмалары белән идарә итү**

1. Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге музей әйберләре һәм музей тупланмалары дәүләт музейларына, башка дәүләт учреждениеләренә оператив идарә итү өчен Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә дәүләт җайга салуын гамәлгә ашыруга вәкаләтле органы тарафыннан үзе билгеләгән тәртиптә тапшырыла.

2. Музей әйберләре һәм музей тупланмалары оператив идарә итү өчен тапшырылган дәүләт музейлары, башка дәүләт учреждениеләре түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

1) музей әйберләренең һәм музей тупланмаларының физик сакланышын һәм иминлеген;

2) бу музей әйберләре һәм музей тупланмаларына бәйле исәпкә алу документларын алып баруны һәм саклауны;

3) музей әйберләрен һәм музей тупланмаларын белем бирү, мәдәни, фәнни, иҗади максатларда куллануны.

3. Татарстан Республикасы милкендәге музей әйберләрен һәм музей тупланмаларын Татарстан Республикасы чикләрендә, шулай ук аннан читтә Россия Федерациясе территориясендә башка музейларга һәм оешмаларга күргәзмә һәм башка максатларда вакытлыча биреп тору Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә дәүләт җайга салуын гамәлгә ашыруга вәкаләтле органы рөхсәте белән башкарыла.

4. Татарстан Республикасы милкендәге һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей әйберләрен һәм музей тупланмаларын читләштерү федераль законнар нигезендә башкарыла.

10 статья. **Татарстан Республикасы территориясендәге музей әйберләре һәм музей тупланмалары торышына дәүләт контроле**

1. Татарстан Республикасы территориясендәге музей әйберләре һәм музей тупланмалары торышына дәүләт контролен мәдәният өлкәсендә дәүләт җайга салуы йөкләнгән федераль орган, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә дәүләт җайга салуын гамәлгә ашыруга вәкаләтле органы үз вәкаләтләре чикләрендә башкаралар.

2. Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше составына кертелгән музей әйберләре һәм музей тупланмалары торышына дәүләт контроле түбәндәге рәвешләрдә гамәлгә ашырыла:

1) музей әйберләренең һәм музей тупланмаларының сакланышын һәм аларны саклау шартларын тикшерү;

2) Россия Федерациясе Музей фондына дәүләт исәп-хисабын ясау өчен музей әйберләре һәм музей тупланмалары турында гарызнамәләр җибәрү һәм мәгълүмат алу.

4 бүлек. **Татарстан Республикасында музей әйберләренең һәм музей тупланмаларының дәүләт каталогы**

11 статья. **Татарстан Республикасында музей әйберләренең һәм музей тупланмаларының дәүләт каталогы**

1. Татарстан Республикасында музей әйберләренең һәм музей тупланмаларының дәүләт каталогы (алга таба – Дәүләт каталогы) Татарстан Республикасы территориясендә даими булган һәр музей әйбере һәм һәр музей тупланмасы турында төп белешмәләргә ия исәп-хисап документы булып тора.

2. Дәүләт каталогына белешмәләр кертү һәм аны алып бару Дәүләт каталогы турында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә дәүләт җайга салуын гамәлгә ашыруга вәкаләтле органы тарафыннан расланган нигезләмә нигезендә башкарыла.

12 статья. **Музей әйберләрен һәм музей тупланмаларын Дәүләт каталогына кертү**

1. Россия Федерациясе милкендәге һәм Татарстан Республикасы милкендәге, Татарстан Республикасының дәүләт, муниципаль, дәүләтнеке булмаган музейларына һәм бүтән юридик затларына тапшырылган музей әйберләре һәм музей тупланмалары Дәүләт каталогына кертелә.

2. Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре милкендә, шулай ук шәхси һәм башка милектәге музей әйберләрен һәм музей тупланмаларын Дәүләт каталогына кертү тиешле экспертиза үткәрелгәннән соң милекченең гаризасы буенча гамәлгә ашырыла.

3. Дәүләт каталогында тиешле фактны теркәү көненнән музей әйберләре һәм музей тупланмалары Дәүләт каталогына кертелгән дип саналалар.

13 статья. **Дәүләт каталогыннан музей әйберләрен һәм музей тупланмаларын чыгару**

1. Дәүләт каталогыннан музей әйберләрен һәм музей тупланмаларын чыгару түбәндәге очракларда башкарыла:

1) музей әйберләре һәм музей тупланмалары югалганда яисә бозылганда;

2) музей әйберләренең һәм музей тупланмаларының башкаларына алмашканда;

3) музей әйберләренең, музей тупланмаларының һәм башка мәдәни кыйммәтләрнең мәдәни-тарихи әһәмияте, физик торышы һәм башка үзенчәлекләре хакында ялгыш бәяләмә бирелгәндә;

4) законнарда каралган башка очракларда.

2. Дәүләт каталогында тиешле фактны теркәү көненнән музей әйберләре һәм музей тупланмалары Дәүләт каталогыннан чыгарылган дип саналалар.

5 бүлек. **Татарстан Республикасында музейлар**

14 статья. **Татарстан Республикасында музейларны төзү. Татарстан Республикасында музейлар төрләре**

1. Татарстан Республикасында музейлар учреждениеләр рәвешендә коммерциячел характерда булмаган мәдәни, белем бирү һәм фәнни функцияләрне гамәлгә ашыру өчен федераль законнарда билгеләнгән максатларда гына төзеләләр.

2. Милек төренә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы территориясендә түбәндәге музейлар эшлиләр һәм оешырга мөмкиннәр:

1) дәүләт;

2) муниципаль (җирлекнең, муниципаль районның, шәһәр округының);

3) дәүләтнеке булмаган.

15 статья. **Татарстан Республикасында музейларны оештыру һәм аларның эшчәнлеге шартлары**

Татарстан Республикасында музейлар үз эшчәнлекләрен түбәндәгеләр булганда гамәлгә ашыралар:

1) саны һәм тарихи-мәдәни кыйммәтләре музей экспозициясе формасында халыкка тәкъдим итүне һәм халыкка күрсәтүне оештыру мөмкинлеген бирә торган музей әйберләре һәм музей тупланмалары;

2) музей әйберләрен һәм музей тупланмаларын саклау һәм халыкка күрсәтү шартларын тәэмин итә торган матди-техник база (биналар, җиһазлар, төзекләндерү, саклауның һәм иминлекнең техник чаралары);

3) эшчәнлекнең барлык төп төрләрен гамәлгә ашыручы музей белгечләре;

4) музей-тыюлыклар (музей-усадьбалар) өчен – мәдәни һәм табигый мирасның тулаем территориаль комплекслары;

5) музей эшчәнлеген финанслауның даими чыганаклары.

16 статья. **Татарстан Республикасында дәүләт музейларын һәм муниципаль музейларны финанслау**

1. Татарстан Республикасында дәүләт музейларын һәм муниципаль музейларны финанслау түбәндәгеләр исәбенә гамәлгә ашырыла:

1) федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетлары акчалары;

2) Татарстан Республикасында музейларның керем китерүче эшчәнлекне билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырудан алынган керемнәре;

3) гражданнардан һәм юридик затлардан кергән хәер һәм башка кире кайтарылмый торган акчалар;

4) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тыелмаган бүтән чыганаклар.

2. Татарстан Республикасы дәүләт музейларын бюджеттан финанслау күләме Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнә.

17 статья. **Татарстан Республикасында дәүләт музейларын һәм муниципаль музейларны урнаштыру**

1. Татарстан Республикасында дәүләт музейларын һәм муниципаль музейларны музей фондларының саклануын һәм иминлеген тәэмин итү таләпләренә, аларны саклау, музей персоналының хезмәтен саклау шартларына туры килми торган һәм карарга килүчеләрнең керүен чикли торган урыннарга (биналарга) урнаштыру рөхсәт ителми.

2. Татарстан Республикасында дәүләт музейларын һәм муниципаль музейларны аларның эшчәнлеге шартларын начарайта торган урыннарга (биналарга) күчерү рөхсәт ителми. Музей урыны (бинасы) башка оешмаларга тапшырылган очракта, милекче музейга шундый ук урын (бина) тәкъдим итәргә һәм музей фондларын, җиһазларын күчерүне финанс ягыннан тәэмин итәргә тиеш.

18 статья. **Татарстан Республикасында музейларга ярдәм итү**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы территориясендә булган һәм дәүләт музейларына, үз эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыра торган бүтән дәүләт учреждениеләренә оператив идарә итүгә тапшырылган музей әйберләрен һәм музей тупланмаларын саклау, куллану һәм халыкка тәкъдим итү өчен кирәкле булган финанс шартларын һәм башка шартларны тәэмин итәргә, шулай ук бу музей әйберләренә һәм музей тупланмаларына китерелгән зыянны каплау өчен кирәкле гарантияләрне (иминиятне дә кертеп) бирергә тиеш.

2. Уникаль тарихи-сәнгать комплексларны саклау буенча өстәмә чаралар күрү зарурлыгына бәйле рәвештә дәүләт музейларына ярдәм күрсәтүнең, шулай ук Татарстан Республикасында илкүләм (россиякүләм) һәм дөньякүләм әһәмияткә ия музей әйберләре һәм музей тупланмалары саклана торган иң эре дәүләт музейлары һәм музей-тыюлыклар эшчәнлеге өчен уңайлы шартлар тудыруның аерым рәвешләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

19 статья. **Татарстан Республикасы музейлары реестры**

1. Татарстан Республикасы музейлары реестрына Татарстан Республикасындагы дәүләт музейлары, муниципаль һәм дәүләтнеке булмаган музейлар турындагы белешмәләр кертелә.

2. Татарстан Республикасы музейлары реестрына белешмәләр кертү һәм аны алып бару Татарстан Республикасы музейлары реестры турында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә дәүләт җайга салуын гамәлгә ашыруга вәкаләтле органы тарафыннан расланган нигезләмә нигезендә башкарыла.

3. Татарстан Республикасы музейлары реестрыннан чыгару музей юкка чыгарылган очракта гамәлгә ашырыла.

6 бүлек. **Татарстан Республикасындагы музейларда саклана торган Россия Федерациясе Музей фонды белән таныша алу мөмкинлеген тәэмин итү**

20 статья. **Музей әйберләре һәм музей тупланмалары белән таныша алу мөмкинлеге**

1. Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән һәм Татарстан Республикасында музейларда булган музей әйберләре һәм музей тупланмалары законнарда билгеләнгән тәртиптә гражданнарның алар белән таныша алу мөмкинлеге өчен ачык.

2. Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән һәм Татарстан Республикасында музейларда булган музей әйберләре һәм музей тупланмалары белән таныша алу мөмкинлегенә чикләүләр милекче яисә ия тарафыннан түбәндәгеләр нигезендә билгеләнә ала:

1) музей әйберләре һәм музей тупланмалары сакланышыннан канәгать булмау;

2) реставрация эшләре үткәрелү;

3) музей әйберенең музейның саклау урынында (депозитариендә) булуы.

3. Музей әйберләре һәм музей тупланмалары белән таныша алу мөмкинлеген цензура максатыннан чикләү рөхсәт ителми.

21 статья. **Музей әйберләрен һәм музей тупланмаларын бастырып чыгару**

1. Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән һәм Татарстан Республикасында музейларда булган музей әйберләрен һәм музей тупланмаларын беренче тапкыр бастырып чыгару хокукы әлеге музей әйберләре һәм музей тупланмалары беркетелгән музейга бирелә.

2. Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән һәм Татарстан Республикасында музейларда булган музей әйберләренең һәм музей тупланмаларының күчермәләрен коммерциячел максатларда файдалану хокукын тапшыру музей әйберләре һәм музей тупланмалары милекчесе билгеләгән тәртиптә музейлар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Музей әйберләренең һәм музей тупланмаларының, музей биналарының, музейлар территорияләрендә урнашкан объектларның сурәтләрен кулланып, шулай ук аларның атамаларыннан һәм символикаларыннан файдаланып, сынлы сәнгать, басма, сувенир һәм башка тиражлы продукция һәм халык куллану товарларын җитештерү музейларның дирекцияләре рөхсәте белән башкарыла.

7 бүлек. **Татарстан Республикасында музей-тыюлыкларның (музей-усадьбаларның) хокукый нигезләмәләре үзенчәлекләре**

22 статья. **Татарстан Республикасында музей-тыюлыклар (музей-усадьбалар)**

1. Татарстан Республикасында музей-тыюлыклар (музей-усадьбалар) түбәндәге эшчәнлекне гамәлгә ашыралар:

1) музей әйберләрен һәм музей тупланмаларын саклауны, ачыклауны һәм туплауны, өйрәнүне, бастырып чыгаруны;

2) тарихи-архитектура ансамбльләренең, тарихи-мәдәни һәм (яисә) табигый комплексларның, тарихи һәм (яисә) табигый мохитнең һәм янәшәсендәге ландшафтларның тулылыгын тәэмин итүне;

3) мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен), табигатьне саклау зоналарын саклауның, өйрәнүнең, куллануның һәм популярлаштыруның иң яхшы шартларын булдыруны;

4) мәдәни-танып белү туризмын үстерүне.

2. Музей-тыюлыклар (музей-усадьбалар) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тыелмаган һәм әлеге Законда, башка законнарда һәм норматив хокукый актларда һәм учреждениенең гамәлгә кую документларында каралган максат һәм бурычларга туры килә торган бүтән эшчәнлекне гамәлгә ашыра алалар.

3. Татарстан Республикасында музей-тыюлыклар (музей-усадьбалар) бары тик дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр буларак гамәлгә куела ала.

23 статья. **Музей-тыюлык (музей-усадьба) территориясе һәм аны карап тоту режимы**

1. Музей-тыюлык (музей-усадьба) территориясе музей-тыюлык (музей-усадьба) территориясе чикләрендә урнашкан мәдәни мирас объектларын, территориаль ресурсларны (җир, урман, су һәм башкалар) һәм күчемсез милекнең бүтән объектларын үз эченә алган тулаем территориаль комплексны тәшкил итә.

2. Музей-тыюлыкларларның (музей-усадьбаларнын) билгеләнгән территорияләре чикләрендәге җирләр (тарихи-мәдәни әһәмияттәге җирләр, табигатьне саклау билгеләнешендәге җирләр) аеруча саклanылучы территорияләр булып саналалар һәм Россия Федерациясе Җир кодексы нормалары, «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон,

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, бүтән законнар һәм норматив хокукый актлар нигезендә гражданнарның чикле таныша алуларындагы территорияләр булып торалар.

3. Музей-тыюлык (музей-усадьба) урнашкан җир кишәрлекләре (территорияләр) аңа даими (сроксыз) файдалану хокукында бирелә.

4. Музей-тыюлык (музей-усадьба) территориясе аеруча кыйммәтенә һәм анда урнашкан мәдәни мирас объектларының кыйммәтенә бәйле рәвештә истәлекле урын булып санала. Музей-тыюлык (музей-усадьба) территориясендә мәдәни мирас объектларына, аның территориясендә урнашкан табигый объектларга һәм комплексларга зыян салырга мөмкин булган, шулай ук аның максатларына һәм бурычларына туры килмәгән һәртөрле эшчәнлек тыела.

5. Музей-тыюлык (музей-усадьба) территориясендә экскурсия, туристлык, мәдәни-массакүләм, кунакханә һәм бүтән эшчәнлекне оештыру тәртибе музей-тыюлык (музей-усадьба) тарафыннан билгеләнә.

6. Музей-тыюлык (музей-усадьба) территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы юридик һәм физик затлар аның өчен билгеләнгән саклау, карап тоту, файдалану һәм эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру режимын сакларга тиеш.

24 статья. **Музей-тыюлыкны (музей-усадьбаны) оештыру тәртибе**

1. Татарстан Республикасында дәүләт музей-тыюлыгын (музей-усадьбасын) оештыру тәртибе истәлекле урыннарны музей-тыюлыкка (музей-усадьбага) кертүне нигезләүне, музей-тыюлыкның (музей-усадьбаның) саклау предметын, музей-тыюлыкны (музей-усадьбаны) оештыру турындагы документларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшыру тәртибен билгеләүне, шулай ук истәлекле урынны музей-тыюлыкка (музей-усадьбага) кертү карарын кабул иткәндә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган документлар составын үз эченә ала.

2. Музей-тыюлыкның (музей-усадьбаның) максатчанлыгын һәм аны халыкка күрсәтү зарурлыгын раслый торган тарихи-мәдәни экспертизаның бәяләмәсе музей-тыюлыкны (музей-усадьбаны) оештыру карарын кабул итү өчен нигез булып тора.

3. Музей-тыюлыкны (музей-усадьбаны) саклау, үстерү һәм халыкка күрсәтү чаралары музей-тыюлыкны (музей-усадьбаны) саклау һәм үстерүнең Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә дәүләт җайга салуын гамәлгә ашыруга вәкаләтле органы боерыгы белән раслана торган генераль планында билгеләнә һәм мәдәни мирас объектларын саклауның, кулलануның, популярлаштыруның һәм дәүләт саклавының республика максатчан программаларында исәпкә алына.

4. Җирле (муниципаль) әһәмияттәге музей-тыюлыкны (музей-усадьбаны) оештыру тәртибе, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә дәүләт җайга салуын гамәлгә ашыруга вәкаләтле органы белән килештереп, Татарстан Республикасы җирлекләренең һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.

8 бүлек. **Йомгаклау нигезләмәләре**

25 статья. **Әлеге Законны бозган өчен җаваплылык**

Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, физик һәм юридик затлар әлеге Закон нигезләмәләрен бозган өчен федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

26 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. 5 статьяның 4 пункты 2011 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 4 бүлеге, 19 статьясы 2012 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керәләр.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 14 октябре
№ 69-ТРЗ